| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЭБАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ — КАРАР

«12» март 2025 ел — Ябалак авылы — № 94

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 22 июлендәге 213-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында һәм http:// ebalak -kaybici.tatarstan.ruвеб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге рәсми сайтында бастырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы — Гыйзәтуллина М.Ф

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге
Советының 2025 елның 12нче
мартындагы 94 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр**

1. 1 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы составына керә.».

2. 5 статьяда:

- 1өлешкә түбәндәге эчтәлекле 23 пункт өстәргә:

«23) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

- 1 өлешнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;»;

- 1 өлешнең 21 һәм 22 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

3. 11 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацында «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны оештыручы һәм уздыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма органы» сүзләренә алмаштырырга.

4. 12 статьяның 3 өлешендәге 3 абзацында «Җирлек яисә» сүзләрен «яисә» сүзенә алмаштырырга.

5. 13 статьяда:

- 5 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны оештыручы һәм уздыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

- 8 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны оештыручы һәм уздыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

- 12 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны оештыручы һәм уздыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.

6. 19 статьяның 10 өлешендә «(яисә)» сүзен төшереп калдырырга.

7. 22 статьяның 4 өлешендәге өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре җирлек Советы тарафыннан җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл итүдә торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләрен яклау критериеннән чыгып билгеләнә.».

8. 29 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек Советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланган 7 депутаттан тора.».

9. 30 статьяның 11 һәм 12 өлешләрендә «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга.

10.33статьяда:

- 27пунктның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны Җирлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасы оештыру;».

- 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 32 пункт өстәргә:

«32) башкарма комитет формалаштыруда катнашу, шул исәптән башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларының, башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләренең урынбасарларын билгеләп кую яисә килештерү, шулай ук мондый катнашуның рәвешләре һәм тәртибе;»;

1 өлешнең 13 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

11. 40 статьяда:

- 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 13.1 пункт өстәргә:

«13.1) аның чит ил агенты статусы алуы;».

12. 43 статьяда:

- 5.1 өлешнең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлек башлыгын үз вәкаләтләре чоры тәмамланганчы Җирлек Советында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү белән азат итү;»;

- 5.1 өлешнең бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы Җирлек Советында вазыйфалар биләүне тыю;»;

- 6 өлешнең 2 пунктында:

«а»пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппаратында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппараты,» сүзләрен һәм «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга.

13. 45 статьяда:

- 8.1 өлешнең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлек башлыгы урынбасары үз вәкаләтләре чоры тәмамланганчыга кадәр Җирлек Советында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү;»;

- 8.1 өлешнең бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы Җирлек Советында вазыйфалар биләүне тыю;»;

-10 өлешнең 2 пунктында:

«а»пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппаратында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппараты,» сүзләрен һәм «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга.

14. 49 статьяда:

- 1 өлешнең 5 пунктында түбәндәге эчтәлекле 8 абзац өстәргә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә ала.».

- 1 өлешнең 6 пунктындагы өченче абзацын төшереп калдырырга;

- 1 өлешнең 6 пунктындагы 1-16 пунктчаларын үз көчен югалткан дип танырга;

15. 51 статьяда:

- 5 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«старостаның вәкаләтләре чоры 5 ел тәшкил итә.»;

- 5 өлешнең икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

- 7 өлештә «әлеге Устав һәм (яисә)» сүзләрен төшереп калдырырга.

16. VII бүлекне һәм 54 статьяны үз көчен югалткан дип таңырга.

1. 59 статьяның 3 өлешендә «һәм Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга.
2. 71 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«71статья Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе

1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючы булып тора торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый

актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) тулы текстны рәсми бастырып чыгару; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында 2013елның 17 декабрендәге ЭЛ ФС77-60244 номерлы таныклык Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) яисә “Кайбыч таңнары” (“Кайбицкие зори”) газетасында, Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында бирелгән 2011 елның 30 ноябрендәге ЭЛ ФС77-47501 номерлы таныклык;

2) Җирлекнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (http://http:// ebalak -kaybici.tatarstan.ru).

3) җирлекнең торак пункты территориясендә махсус мәгълүмат стендында хокукый акт текстын урнаштыру: Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ябалак авылы, Якты урамы, 4 йорт

3. Гражданнарның Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталыннан файдалана алуын тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә түбәндәге адрес буенча тоташу пунктлары эшли: Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ябалак авылы, Якты урамы, 4 йорт

4. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, таратуы федераль закон белән чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, килешүләр аларны имзалаган көннән алып 10 көн эчендә халыкка игълан ителә.

5. Салымнар һәм җыемнар турында җирлек Советының норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзе тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, имза салынган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне, халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге Җирлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.».

1. 74 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары муниципаль милектәге электр челтәре оешмасы яисә Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эшләүче территориаль челтәр оешмасы яисә территориаль челтәр оешмасы системасындагы электр энергетикасы турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән

очракларда, тәртиптә һәм шартларда электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм алардан файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.».

1. 81 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер мәртәбә бирелә торган түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә әлеге Уставның 22 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.».